

Медицина хезмәткәре конен быел 18 июньдә (киләсе елда – 16.06.) бәйрәм иттек. Бу профессия вәкилләренә һәрвакыт рәхмәтле без. Алар турында бәйрәм конне генә тvгел, еш язсак та аз булыр, дип уйлыйм.
Зульфия Шамиль кызы Дулатова жан чакыруы буенча кvпкырлы һәм мавыктыргыч медицина мохитенә әләгә һәм vзен рак кебек житди һәм котелмәгән авыру белән корәшкә багышлау очен анын ин катлаулы олкәсен – онкологияне сайлый, дип яза Семен Кильгишов “Торбеевские новости” газетасында. - Анын эшендә мәжбvри сыйфатлар булып профессионализм, игелеклелек һәм шәфкатьлелек тора.      Бу сvзләргә нигез буларак Зульфия Шамиль кызынын тvбәндәге фикере тора.
- Чын фән кvп нәрсә эшли ала. Хәзерге вакытта момкин булмаган нәрсә кайчандыр гамәлгә кертеләчәк һәм киләчәктә хакыйкать булып чыгачак; һәрвакыттагыча (постоянно) бер генә нәрсә остенлек ала - кеше ярату. Боек медицина реформаторы Парацельснын билгеле жомләсе бар: «Табибнын йорәгендәге коче, дарунын ин зур нигезе – мәхәббәт», - ди Зульфия Шамиль кызы Дулатова медицина хезмәткәрләре турында.
Язма героебыз белән кыскача таныштырып алабыз. Зульфия Шамиль кызы Дулатова табиб булачагын ул балачактан ук белгән. Мәктәптә укыганда гербарияләр този, шифалы vсемлекләр жыя һәм киптерә. Максатына ныклап барып, vз - vзен онытып, беренче пациентларын - йомшак уенчыкларны, курчакларны, бераз сонрак - ярдәм таләп иткән урамдагы жәрәхәтләнгән хайваннарны дәвалый. Зульфия Шамиль кызы мәктәпне тәмамлап Н.П.Огарев исемендәге университетнын медицина факультетына белем алырга керә һәм аны 2000 елда унышлы тәмамлагач, Торбеево vзәк район хастаханәсендә мостәкыйль хезмәт эшчәнлегенә керешә.
Шул вакыттан бирле ул vз пациентлары очен дәвалаучы табиб кына тvгел, ә шулай ук психолог та. Шамиль кызы Зульфия котылгысыз хәлне факт итеп кабул итәргә, куркуларны һәм кичерешләрне жинәргә, ихтыяр кочен табарга, омет уятырга һәм авыруны жинvгә ышаныч уятырга ярдәм итә. Чынлап та, табибларнын кочләре -

йорәкләрендә. Ә дәвалау могжизалары авырулар караваттан кvтәрелгәч була. Аларнын кvбесе ак халатлы, батырлыгы, чиксез игелеге, назлылыгы, жылы карашы, илаһи нурлар белән яктыртылган кебек, йомшак бәрхет тавышы, авыртуны һәм кайгыларны баса торган бу сойкемле хатын-кыз алдында башларын тvбән иеп торалар. Ләкин унышлар артында кvрәзәчеләр һәм сихерчеләр тvгел, ә Зульфия Шамиль кызы Дулатова һәм анын хезмәттәшләре кебек фидакарь табиблар тора; алар башкаларнын исәнлеге очен vзләрен кызганмыйча эшлиләр.
Табигать авыруны китереп чыгара да, дәвалый да, шуна кvрә анын кvренгән һәм кvренмәгән процессларын, шулай ук аларнын якын һәм ерак нәтижәләрен белергә кирәк. Онкология белгечлеге медицинанын тар тармагы дип уйлау дорес тvгел. Диагнозны дорес кую, анын яман шеш формасыннан авырунын яхшы барышын тану очен иммунология, фармакология, эндокринология, пульмонология, гинекология, гематология кебек олкәләрдә кин белемгә ия булырга кирәк, дип сойли Зульфия Шамильевна Дулатова.
Әмма шуны онытмаска кирәк, егерме беренче гасырнын Россия табибы - биология, химия, физика олкәсендәге генә белгеч тvгел, ә боек Н.Пирогов, Н. Склифософский, Л.Рогозов һәм башкалар тарафыннан салынган традицияләрнен варисы; тарих, философия, мәдәни жәмгыять тенденцияләре белгече, кин кvзаллауга, ижади сәләтләргә ия. Бу критерийларнын барысына да бvгенге хикәянен герое Зульфия Шамиль кызы Дулатова – искиткеч табиб, кvп балалы әни, кайгыртучан хатын, «Мордовия хатын-кызлары берлеге» ижтимагый оешмасынын активистына тулысынча туры килә.

**Наилә НАСЫРОВА**